**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адресы: 422870, РТ, БазарлыМатакавылы, Крайновур., 56
тел: тел: 8 (84346) 2-17-60

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** .Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021елның 26 октябре 455№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 14 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясе турында» 108 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 14 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясе турында» 108 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче кушымтага

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Административ комиссия әгъзасы итеп суд карары белән хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган, законда билгеләнгән тәртиптә алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә, тикшерү изоляторларында яисә вакытлыча тоту изоляторларында һәм сак астында тоту өчен башка урыннарда булган, авыру нәтиҗәсендә аларга административ комиссия әгъзасы вәкаләтләрен үтәүгә комачаулый торган зат билгеләп куела алмый.»;

16 пунктның 8 пунктчасын төшереп калдырырга;

19 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) карар күчермәләрен тапшыруны яисә җибәрүне тәэмин итә;»;

20 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Күрсәтелгән срок узганнан соң, административ комиссия яңа составтагы административ комиссиянең беренче утырышы көненә кадәр үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәвам итә.»;

21 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.Административ комиссия әгъзасының вәкаләтләре аны билгеләп куйган җирле үзидарә органы тарафыннан түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:»;

21 пунктта түбәндәге эчтәлекле 7.1 пунктча өстәргә:

«7.1)Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;»;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Башкарма комитет административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын билгели»;

29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Административ хокук бозулар турында эшләрне карау Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тәэмин ителә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче: И. В. Юсупов